| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Крындинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кырынды авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2021 Кырынды № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын беренче этабын 2022 елның 11 ноябрендә 13 сәг 00 мин билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын икенче этабын 2022 елның 11 ноябрендә 15 сәг 00 мин билгеләргә.

3.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын өченче этабын 2022 елның 11 ноябрендә 17 сәг 00 мин билгеләргә.

4.Яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә:
- 1 этап: Киров урамында, Крынданың Совет урамында яшәүчеләр.

- 2 этап: К.Маркс урамында, Кырынданың Полевая урамында яшәүчеләр.

- 3 этап: Кооператив урамында, К.Маркс Пер., Крынды авылында яшәүчеләр.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге

1.МТЗ-82.1 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу.

2. Кырынды авылында су белән тәэмин итү өчен тирәнтен насослар һәм материаллар сатып алу, ремонт һәм башка хезмәтләр күрсәтү.

3. Авылда урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру Чишмә авылында , контракт буенча электрик эшенә түләү һәм башка агымдагы чыгымнар.

4. Кырынды авылында аварияле коры агачларны кисү һәм сүтү.

5. Чишмәне төзекләндерү, материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча түләү, Крынды авылында урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Чишмә авылы, Миникаев урамы, 17, кибет янында үткәрергә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы

Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

(https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.А.Нафиков